**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Положение о лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами

1. Внести в Положение о лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 3 мая 2018 года № УП-346 «О создании лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 24 января 2019 года № УП-21 и от 1 февраля 2021 года № УП-71), следующие изменения:

а) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Комиссия руководствуется в своей деятельности Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, указами и распоряжениями Президента Российской Федерации, постановлениями и распоряжениями Правительства Российской Федерации, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Президента Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.»;

б) подпункт «в» пункта 4 изложить в следующей редакции:

«в) участие в организации регионального государственного лицензионного контроля за осуществлением предпринимательской деятельности по управлению многоквартирными домами;»;

в) подпункт «в» пункта 5 изложить в следующей редакции:

«в) принимает участие в организации регионального государственного лицензионного контроля за осуществлением предпринимательской деятельности по управлению многоквартирными домами, проводимого лицензирующим органом в отношении соискателя лицензии;».

2. Настоящий Указ вступает в силу со ~~дня~~ его подписания.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
08 октября 2022 года
№ УП-724

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 24 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы һәм 2021 елның 1 февралендәге ПУ-71 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.»;

б) 4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга төбәк дәүләт лицензия контролен оештыруда катнашу;»;

в) 5 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) лицензия алырга теләүчегә карата лицензия бирүче орган тарафыннан уздырыла торган күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга төбәк дәүләт лицензия контролен оештыруда катнаша;».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 08 октябрь
№ ПУ-724